РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
СЮНДЮКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӨЕНДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 50-7-27, факс 50-7-27

# КАРАР

**29 октябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 12 ноябрендә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Сөендек авыл Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Сөендек авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү;

- Сөендек авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелискны төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Сөендек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Сөендек авыл җирлеге башлыгы** **Х.А. Измайлов**